Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Олы Бакырчы авылында гражданнар җыенының
«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Олы Бакырчы авылында 2021 елда гражданнар җыены нәтиҗәләре һәм үзара салым кертү турында» 2020 елның 25нче ноябрендәге 1нче номерлы карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Олы Бакырчы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш),500 (биш йөз) сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертүгә рөхсәт итәсезме »дигән мәсьәлә буенча 2020 елның 25нче ноябрендә Бакырчы авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде,һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкарырга җибәрергә:

- вак таш җәю һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту юлы белән автомобиль юлларын ремонтлау;
- территорияне төзекләндерүне оештыру».

«ӘЙЕ» «ЮК»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 339 кеше кертелгән,җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 173 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенында катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 173 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәгечә карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче Бакырчы авыл җирлегенең Олы Бакырчы авылында халык җыенын, халык җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2."Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Олы Бакырчы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляска инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш) 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме дигән сорау буенча кабул ителгән карарны танырга һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- вак таш җәю һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту юлы белән автомобиль юлларын ремонтлау;
- территорияне төзекләндерүне оештыру».

3.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Олы Бакырчы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш) 2021 елда 500 (биш йөз) сум

күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- вак таш җәю һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту юлы белән автомобиль юлларын ремонтлау;
- территорияне төзекләндерүне оештыру».

4.Гражданнар җыенының нәтиҗәләрен мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

Бакырчы авыл җирлеге Башлыгы Ф. Х. Вәлиев